## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Шекәнәч авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

"19" ноябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №126 карары нигезендә, 2023 елның 19 ноябрендә «Сез 2024мм елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яше тулган һәм тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларнын гаилә әгъзаларыннан, РФ Оборона министрлыгы белән контракт тозегән хәрби хезмәткәрләрдән һәм РФ Оборона министрлыгы белән контракт тозегән хәрби хезмәткәрләрнең гайлә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү буенча түбәндәге эшләрне башкару:

1) Шекәнәч авылы Пионер һәм Татарстан урамнары территорияләрен төзекләндерү һәм чистарту (үлән кисү, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү, кисү материалларыннан һәм чүп-чардан каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр чистарту);

2) Шекәнәч авылы зиратын карап тоту һәм төзекләндерү (үлән кисү, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү, кисү материалларыннан һәм чүп-чардан каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр чистарту);

3) Шекәнәч авылынын буаны ремонтлау һәм төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу һәм килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

«2022 елда гражданнар җыены белән билгеләнгән буаны ремонтлау һәм төзекләндерү өчен 40000 сум күләмендә гражданнарның кулланылмаган үзара салымы акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

1) буаны ремонтлау һәм төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу һәм килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

**Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:**

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 84 (сиксән дүрт ) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 72 (җитмеш ике) кеше, 85,7 %.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 67 (алтмыш җиде) кеше тавыш бирде, 93,1%;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 5 (биш) кеше тавыш бирде,6,9%.

**Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:**

**1.** Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Шекәнәч авылында узган халык җыенын **- узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.**

Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яше тулган һәм тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларнын гаилә әгъзаларын, РФ Оборона министрлыгы белән контракт тозегән хәрби хезмәткәрләрдән һәм РФ Оборона министрлыгы белән контракт тозегән хәрби хезмәткәрләрнең гайлә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү буенча түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Шекәнәч авылы Пионер һәм Татарстан урамнары территорияләрен төзекләндерү һәм чистарту (үлән кисү, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү, кисү материалларыннан һәм чүп-чардан каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр чистарту);

2) Шекәнәч авылы зиратын карап тоту һәм төзекләндерү (үлән кисү, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү, кисү материалларыннан һәм чүп-чардан каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр чистарту);

3) Шекәнәч авылынын буаны ремонтлау һәм төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу һәм килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

2022 елда гражданнар җыены белән билгеләнгән буаны ремонтлау һәм төзекләндерү өчен 40000 сум күләмендә гражданнарның кулланылмаган үзара салымы акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

1) буаны ремонтлау һәм төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу һәм килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү) - **мәсьәләсен кабул итәргә**.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Шекәнәч авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Шекәнәч авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма
комитет җитәкчесе: Порфирьев С.Н.